# Ярты гасырлык сер

# Шәймәрдәнов Зөлфәт Шәүкәт улы



Мин - Шәймәрдәнов Зөлфәт Шәүкәт улы. Түбән Кама районы Югары Чаллы гомуми урта белем бирү мәктәбенең 8 нче сыйныф укучысы



Әнием Шәймәрдәнова Мөслимә Габделхәй кызы – татар теле укытучысы. Ул буш вакытларында авылыбыз тарихын, җирле атамаларны, авылдашларыбыз иҗатын өйрәнә.





Әнием туплаган бәетләрне бастырсаң, бер китап булыр иде.




Бәетләр язылган кәгазь битләренә күпме кайгы-сагыш, сабырлык һәм үткәннәрне ихтирам белән искә алу сыйган. Быел да бу папка тагын бер бәет белән үзәк өзгеч вакыйганы үз эченә алды.





Кулымда 55 ел буе сер булып сакланган табыш - ул минем бабамның шигырьләре язылган калын дәфтәр




Армия сафларында хезмәт итүче бабам туган ягын сагынганда шигырьләр язып юанган. Игътибарны җәлеп иткән “Сәлим бәете” үзе генә дә 86 строфадан тора.



Бабам Әхтәмов
Габделхәй Сабир улы,
ул инде 80 яшендә.
Күзләре күрмәсә дә
(бабам хәзер дөм
укыр), үзе язган
“Сәлим бәете”н ул
дулкынланусыз
тыңлый алмый.



Бабамның кайчандыр шигырьләр язуын анын белән 58 ел бергә гомер итүче Тәслимә әбием дә белмәгән.



55 ел буе
якыннарыннан да
сер итеп сакланган
бабам дәфтәре
очраклы рәвештә
табылды. Озын бер
поэма итеп язылган
“Сәлим бәете” белән
мин сезне дә тиздән
таныштырырмын.